ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ТИМЯШЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТИМӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 27 марты № 5

Лениногорск муниципаль районы
«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башкарма
комитетының 2018 елның 25 июлендәге
10 номерлы карары белән расланган
Адреслар бирү, үзгәртү һәм аннулировать
итү буенча Административ регламентка
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 21 декабрендәге «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм көчен югалткан дип тану турында»гы 1622нче номерлы карарына нигезендә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль закон, Татарстан Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 880нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 25 июлендәге 10 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм аннулировать итү буенча Административ регламентка түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.5 пунктның 10нчы абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерцияле булмаган дача оешмалары урнашу территорияләре» дигәнне «гражданнарның үз кирәкләре өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару территориясе» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Тимәш авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмати стендларда һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
"Тимәш авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.М.Сираев